**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
26.06.2024 № 684

Күп балалы гаилә статусын билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә, күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары бирү максатларында һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «күп балалы гаилә статусын билгеләү турында» 2024 елның 18 июнендәге 20-09/8480 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы мәгариф оешмаларында муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә, күпбалалы гаиләләргә ташламалар бирелгәндә, федераль дәрәҗәдә бердәм таныклык үрнәге билгеләнгәнче, балалар туу турындагы таныклык яисә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү (күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аны озайту һәм алмаштыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын билгеләү турында" 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгы белән расланган күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында карар нигезендә ташламалар һәм хезмәтләр күрсәтергә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин